РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 1 » декабрь 2021 ел г. Альметьевск № 1712

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Дәүләт милкендә яисә муниципаль милектә булган җирләрдән яисә җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 25 июнендәге 913 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, 2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар, гавами сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2015 елның 5 июнендәге 416 номерлы карары белән расланган «Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар, гавами сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 12 ноябрендәге 1065 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Дәүләт милкендә яисә муниципаль милектә булган җирләрдән яисә җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 25 июнендәге 913 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

Зак. № 305-2000

2.6.1. пунктының 7) пунктчасы, 2.8.2. пунктының 13) пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов